**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 15 - 18.01.2021

# Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә :

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 1 сентябрендәге 315 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (5 нче кушымта)

2.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмаган очракта гамәлгә ашырыла.»;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә::

9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар турында белешмәләр.»;

3.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Комиссия гаризасын карау

Комиссия үз утырышында социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләрне исәпкә алу эшен һәм документларны карый.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия карары.»;

3.6.1 пунктында

беренче абзацта "комиссия" сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «күрсәтмә проекты» сүзләрен «исәпкә кую турында күрсәтмәләр проектлары " сүзләренә алмаштырырга»;

дүртенче абзацта "комиссия" сүзен төшереп калдырырга

2.Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча җитәкче урынбасары  А. М. Хәсәновка йөкләргә.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**